КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 31 октябрь г.Казань № 965

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 31 май, 412 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 31 май, 412 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

VI бүлектә:

1 нче пунктның 1.1 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Стимуллаштыру характерындагы түләүләр түбәндәгеләрне үз эченә ала:

квалификация категориясе өчен түләүләр;

белем бирү программасының үзенчәлеге өчен түләүләр;

дәүләт бүләкләре булган өчен түләүләр;

юнәлеш буенча эш стажы өчен түләүләр;

хезмәт интенсивлыгы өчен түләүләр;

премияләр һәм башка бүләкләү түләүләре;

башкарылган эшләр сыйфаты өчен түләүләр.»;

9 нчы пунктында «(«башлангыч мәктәп – балалар бакчасы», «прогимназия» статуслары булганнардан тыш)» сүзләрен төшереп калдырырга;

4 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Россия Федерацисе, Совет Социалистик Республикалар Союзы, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындлагы союз һәм автоном республикалар һәм Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре булган өчен түләүләр

беренче һәм икенче дәрәҗдәге укыту-ярдәмче персонал вазыйфаларының һөнәр квалификация төркеменә керүче мәгариф хезмәткәрләре вазыйфалары буенча бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$B_{pz} = O_d \times D_{pz},$$

монда:

$B_{pz}$ – дәүләт бүләкләре булган өчен түләү;

$O_d$ – гомуми белем бирү оешмаларында мәгариф хезмәткәрләре вазыйфаи оклады;

$D_{pz}$ – дәүләт бүләкләре булган өчен өстәмә түләү күләме.

Россия Федерациясенең, Совет Социалистик Республикалар Союзының, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның дәүләт бүләкләре булган өчен өстәмә түләү күләме 7 процент тәшкил итә.

Татарстан Республикасының (Совет Татар Автоном Социалистик Республика) дәүләт бүләкләре булган өчен өстәмә түләү күләме 6 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясе, Россия Федератив Совет Социалистик Республикалары, Татарстан Республикасы, Совет Социалистик Республикалар Союзы, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның тармак бүләкләре булган өчен  өстәмә түләү күләме 4 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясенең Мактау кәгазе булган өчен өстәмә түләү күләме 2 процент тәшкил итә. Россия Федерациясенең Мактау кәгазе булган өчен өстәмә түләү Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының ведомство бүләкләре белән бүләкләү тәртибе нигезендә Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министры (Россия Федерациясе Мәгариф министры) приказы белән бүләкләнә торган мәгариф хезмәткәрләренә билгеләнә (Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы).

«Мәгарифтәге казанышлар өчен» Татарстан Республикасы күкрәк билгесе булган өчен өстәмә түләү күләме 2 процент тәшкил итә. «Мәгарифтәге казанышлар өчен» Татарстан Республикасы күкрәк билгесе булган өчен өстәмә түләү Татарстан Республикасының мәгариф һәм фән министры боерыгы нигезендә билгеләнә (Татарстан Республикасы мәгариф министры).

Булган өчен мәгариф хезмәткәрләренә тиешле түләүләр бирелә торган дәүләт һәм ведомство бүләкләре исемлеге әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымтада китерелгән.»;

түбәндәге эчтәлекле 8.2 нче пункт өстәргә:

«8.2. Эшчәнлек үзенчәлеге өчен түләүләр мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләргә бирелә һәм түбәндәге формула буенча хисаплап чыгарыла:

$$B_{sd} = O_d \times D_{sd},$$

монда:

$B_{sd}$ – эшчәнлек үзенчәлеге өчен түләүләр;

$O_d$ – гомуми белем бирү оешмаларында мәгариф хезмәткәрләре вазыйфаи оклады;

$D_{sd}$ – эшчәнлек үзенчәлеге өчен 9 процентка тигез кабул ителә торган өстәмә күләме.»;

13 нче пунктта:

беренче, дүртенче, алтынчы абзацларда һәм 11 таблицаның исемендә «Эшнең катлаулылыгы» сүзләрен «хезмәт интенсивлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

15 нче пунктта:

15.3 нче пунктчаның тугызынчы абзацында «мәктәпкәчә белем бирү оешмасының» сүзләрен «гомуми белем бирү оешмасының» сүзләренә алмаштырырга;

15.11 нче пунктчаның бишенче абзацында «мәктәпкәчә белем бирү оешмасының» сүзләрен «гомуми белем бирү оешмасының» сүзләренә алмаштырырга;

VII бүлектә:

4 нче пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

$$«B_{kh} = O_b \times D_{kh} \times \frac{H_{fk}}{H_N},»;$$

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$O_b$ – әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган гомуми белем бирү оешмаларында хезмәткәрләрнең база оклады күләме;»;

9 нчы пунктның 15 таблицага түбәндәге эчтәлекле 12 нче пункт өстәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «12. | Үсешләрендә тайпылышлары булган белем алучылар, тәрбияләнүчеләр өчен адаптив белем бирү программаларын тормышка ашыручы гомуми белем бирү оешмаларында эшләү | әйдәп баручы звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре | - | 4,5»; |

VIII бүлекнең 16 таблицасында:

2 графаның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Күләм күрсәткече мәгънәсе (уку елы башлану торышына укучылар, тәрбиячеләр саны, кеше*»;

асъюлны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«*Адаптацияләнгән белем бирү программаларын тормышка ашыручы девиант тәртипле укучылар өчен ябык төрдәге гомуми белем бирү оешмасында, җинаять-үтәтү системасының төзәтү учреждениеләре каршындагы белем бирү оешмаларында, озак дәвалауга мохтаҗ балалар өчен шифаханә төрендәге белем бирү оешмаларында укучылар контингенты 3 коэффициенты белән исәпләнә.

Гомуми белем бирү оешмалары каршында интернатларда яшәүче укучылар

контингенты 2 коэффициенты белән исәпләнә.

Гомуми белем бирү оешмаларының мәктәпкәчә төркемнәрендә тәрбияләнүчеләр контингенты 1,5 коэффициенты белән исәпләнә.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы мәктәпкәчә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

V бүлектә:

1 нче пунктның 1.1 нче пунктчасындагы дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«хезмәт интенсивлыгы өчен түләүләр;»;

4 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Россия Федерациясенең, Совет Социалистик Республикалар Союзының, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш һәм автоном республикаларның һәм Татарстан Республикасының дәүләт бүләкләре булган өчен түләүләр беренче һәм икенче дәрәҗдәге укыту-ярдәмче персонал вазыйфаларының һөнәр квалификация төркеменә керүче мәгариф хезмәткәрләре вазыйфалары буенча бирелә һәм түбәндәге формула буенча хисаплап чыгарыла:

$$B_{pz} = O_d \times D_{pz},$$

монда:

$B_{pz}$ – дәүләт бүләкләре булган өчен түләү;

$O_d$ – гомуми белем бирү оешмаларында мәгариф хезмәткәрләре вазыйфаи оклады;

$D_{pz}$ – дәүләт бүләкләре булган өчен өстәмә түләү күләме.

Россия Федерациясенең, Совет Социалистик Республикалар Союзының, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның дәүләт бүләкләре булган өчен өстәмә түләү күләме 7 процент тәшкил итә.

Татарстан Республикасының (Татар Автоном Совет Социалистик Республикасы) дәүләт бүләкләре булган өчен өстәмә түләү күләме 6 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясе, Россия Совет Федератив Социалистик Республикалар, Татарстан Республикасы, Совет Социалистик Республикалар Союзы, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның тармак бүләкләре булган өчен өстәмә түләү күләме 4 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясенең Мактау кәгазе булган өчен өстәмә түләү күләме 2 процент тәшкил итә. Россия Федерациясенең Мактау кәгазе булган өчен өстәмә түләү Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының ведомство бүләкләре белән бүләкләү тәртибе нигезендә Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министры (Россия Федерациясе Мәгариф министры) приказы белән бүләкләнә торган мәгариф хезмәткәрләренә билгеләнә (Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы).

«Мәгарифтәге казанышлар өчен» Татарстан Республикасы күкрәк билгесе булган өчен өстәмә түләү күләме 2 процент тәшкил итә. «Мәгарифтәге казанышлар өчен» Татарстан Республикасы күкрәк билгесе булган өчен өстәмә түләү Татарстан

Республикасының мәгариф һәм фән министры приказы нигезендә билгеләнә (Татарстан Республикасы мәгариф министры).

Булган өчен мәгариф хезмәткәрләренә тиешле түләүләр бирелә торган дәүләт һәм ведомство бүләкләре исемлеге әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымтада китерелгән.»;

6 нчы пунктта:

беренче һәм икенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Хезмәт киеренкелеге өчен түләүләр мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында педагогика хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә һәм структур бүлекчә җитәкчеләренә бирелә һәм үбәндәге формула буенча хисаплап чыгарыла:

$$«B_{sr} = (O_b \times \frac{H_f \times Y_f}{H_N \times Y_N} + P) \times D_{sr},»;$$

дүртенче, алтынчы абзацларда «эшнең катлаулылыгы һәм киеренкелеге» сүзләрен «хезмәт интенсивлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«P – китап-басма продукция һәм вакытлы матбугат белән тәэмин итүгә 100 сум күләмендәге компенсация, уку-укыту нагрузкасына пропорциональ рәвештә, әмма төп эш урыны буенча бер ставкадан арттырмыйча билгеләнә»;

11 нче пунктта:

беренче, дүртенче, алтынчы абзацларда һәм 8 таблицаның исемендә «эшнең катлаулылыгы» сүзләрен «хезмәт интенсивлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

VI бүлектә:

1 нче пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«нормаль шартлардан тайпылган шартларда эшләгән өчен түләүләр (төрле квалификациядәге эшләрне башкарганда, һөнәрләрне (вазыйфаларны), эш сәгатеннән тыш эшне, төнге вакытта эшне бергә башкаргада һәм нормаль шартлардан тайпылган башка шартларда эшләр башкарганда);»;

4 нче пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

$$«B_{kh} = O_b \times D_{kh} \times \frac{H_{fk}}{H_N},»;$$

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$O_b$ – әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителгән мәктәпкәчә белем бирү оешмасы хезмәткәрләренең база оклады күләме;»;

6 нчы пунктның икенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

11 таблицаның 1 нче пунктындагы 2 графада «тәрбияләнүчеләр өчен» сүзләре алдыннан «туберкулез интоксикациясе булган,» сүзләрен өстәргә;

8 нче пунктның беренче абзацында «мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында» сүзләре алдыннан «адаптив белем бирү программаларын тормышка ашыручы» сүзләрен өстәргә;

VII бүлекнең 12 таблицадагы асъюлны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«*Адаптив белем бирү программаларын тормышка ашыручы мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында тәрбияләнүчеләр контингенты 3 коэффициенты белән исәпкә алына.

Туберкулез интоксикациясе булган балалар өчен мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында тәрбияләнүчеләр контингенты 2 коэффициенты белән исәпкә алына.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы өстәмә белем бирүче мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

V бүлекнең 4 нче пунктындагы беренче абзацында «5.1 нче һәм 5.2 нче пунктлар белән билгеләнгән» сүзләрен «V бүлекнең 1 – 3 нче пунктлары белән билгеләнгән» сүзләренә алмаштырырга;

VI бүлектә:

1 нче пунктның 1.1 нче пунктчасындагы алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бяән итәргә:

«хезмәт интенсивлыгы өчен түләүләр;»;

11 таблицаның 1 графасында:

башисемендә «Т/с» сүзләрен «Квалификация дәрәҗәсе» сүзләренә алмаштырырга;

1 нче пунктта «1.» санын «Беренче квалификация дәрәҗәсе» сүзләренә алмаштырырга;

2 нче пунктта «2.» санын «Икенче квалификация дәрәҗәсе» сүзләренә алмаштырырга;

3 нче пунктта «3.» санын «Өченче квалификация дәрәҗәсе» сүзләренә алмаштырырга;

4 нче пунктның 4.8 нче пунктчасында:

беренче, дүртенче, алтынчы абзацларда һәм 16 таблицаның исемендә «эшнең катлаулылыгы» сүзләрен «хезмәт интенсивлылыгы» сүзләренә алмаштырырга;

5 нче пунктның 5.2: нче пунктчасында

сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$D_{sd}$ – 7 процентка тигез кабул ителә торган олимпия резервы махсуслашкан оешмаларында (бүлекләрендә) эшчәнлек үзенчәлеге өчен өстәмә күләме;»;

унөченче абзацта «адаптив физик культура буенча» сүзләрен төшереп калдырырга;

7 нче пунктта «гомуми белем бирү оешмаларының» сүзләрен «өстәмә белем бирү оешмаларының» сүзләренә алмаштырырга;

7.2 нче пунктчада «гомуми белем бирү оешмаларының» сүзләрен «өстәмә белем бирү оешмаларының» сүзләренә алмаштырырга;

VIII бүлектә:

5 нче пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«өстәмә белем бирү оешмаларында җитәкчегә башкарыла торган эшләре сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр 28 таблицада китерелә.»;

өченче абзацта «стимуллаштыру характерындагы» сүзләре алдыннан

«башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен» сүзләрен өстәргә;

6 нчы пунктта:

икенче җөмләдә «стимуллаштыру характерындагы түләүләр» сүзләре алдыннан «башкарыла торган эшләре сыйфаты өчен» сүзләрен өстәргә;

өченче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләрнең чик күләме өстәмә белем бирү оешмасы җитәкчесенә стимуллаштыру характерындагы түләүләрнең 70 процентына кадәр күләмдә билгеләнә.»;

исемендә һәм 28 таблицаның 4 графасы башисемендә «стимуллаштыру характерындагы түләүләр» сүзләре алдыннан «башкарыла торган эшләре сыйфаты өчен» сүзләрен өстәргә;

8 нче пунктта:

беренче абзацта «Сыйфат өчен түләүләр» сүзләрен «Сыйфат өчен стимуллаштыру түләүләре» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта пятом «стимуллаштыру характерындагы түләүләр» сүзләре алдыннан «башкарыла торган эшләре сыйфаты өчен» сүзләрен өстәргә;

9 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Физик культура һәм спорт өлкәсендә эшчәнлеген гамәлгә ашыручы өстәмә белем бирү оешмасын гамәлгә куючы күрсәтелгән оешма җитәкчесенә тренер-укытучыларга ярышларда уңышлы катнашкан югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен һәм спортчыларга һәм спортчы-интрукторларга ярышларда алынган нәтиҗәләре өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр билгели ала.

Физик культура һәм спорт өлкәсендә эшчәнлеген гамәлгә ашыручы өстәмә белем бирү оешмасы җитәкчесе оешма җитәкчесе урынбасарларына тренер-укытучыларга ярышларда уңышлы катнашкан югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен һәм спортчыларга һәм спортчы-интрукторларга ярышларда алынган нәтиҗәләре өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр билгели ала.

Физик культура һәм спорт өлкәсендә эшчәнлеген гамәлгә ашыручы өстәмә белем бирү оешмасы, һөнәри белем бирү оешмасы җитәкчесенә, җитәкчесе урынбасарларына тренер-укытучыларга ярышларда уңышлы катнашкан югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен һәм спортчыларга һәм спортчы-интрукторларга ярышларда алынган нәтиҗәләре өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләрне гамәлгә ашыруга чираттагы финанс елына чыгымнар күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$V_{VKS_{ruk_i}} = \frac{\sum V_{VKS_{ruk_{svod}}}}{\sum V_{VKS_{tren-pred_{svod}}}} \times \sum V_{VKS_{tren-pred_i}},$$

монда:

$V_{VKS_{ruk_i}}$ – физик культура һәм спорт өлкәсендә эшчәнлеген гамәлгә ашыручы i-нче өстәмә белем бирү оешмасы, һөнәри белем бирү оешмасы җитәкчесенә, җитәкчесе урынбасарларына тренер-укытучыларга ярышларда уңышлы катнашкан югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен һәм спортчыларга һәм спортчы-интрукторларга ярышларда алынган нәтиҗәләре өчен стимуллаштыру

характерындагы түләүләрне гамәлгә ашыруга чираттагы финанс елына чыгымнар күләме;

$V_{VKS_{ruk_{svod}}}$ – физик культура һәм спорт өлкәсендә эшчәнлеген гамәлгә ашыручы өстәмә белем бирү оешмасы, һөнәри белем бирү оешмасы җитәкчесенә, җитәкчесе урынбасарларына тренер-укытучыларга ярышларда уңышлы катнашкан югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен һәм спортчыларга һәм спортчы-интрукторларга ярышларда алынган нәтиҗәләре өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләрне гамәлгә ашыруга агымдагы финанс елына кадәрге елдагы гомуми чыгымнар күләме;

$V_{VKS_{tren-pred_{svod}}}$ – физик культура һәм спорт өлкәсендә эшчәнлеген гамәлгә ашыручы өстәмә белем бирү оешмасы, һөнәри белем бирү оешмасы тренер-укытучыларына ярышларда уңышлы катнашкан югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен һәм спортчыларга һәм спортчы-интрукторларга ярышларда алынган нәтиҗәләре өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләрне гамәлгә ашыруга агымдагы финанс елына кадәрге елдагы гомуми чыгымнар күләме;

$V_{VKS_{tren-pred_i}}$ – физик культура һәм спорт өлкәсендә эшчәнлеген гамәлгә ашыручы i-нче өстәмә белем бирү оешмасы, һөнәри белем бирү оешмасы тренер-укытучыларына айлык түләүләр түләүгә ярышларда уңышлы катнашкан югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен һәм спортчыларга һәм спортчы-интрукторларга ярышларда алынган нәтиҗәләре өчен айлык түләүләр түләүгә чираттагы финанс елына чыгымнар күләме.

Физик культура һәм спорт өлкәсендә эшчәнлеген гамәлгә ашыручы өстәмә белем бирү оешмасы, һөнәри белем бирү оешмасы җитәкчесенә, җитәкчесе урынбасарларына тренер-укытучыларга ярышларда уңышлы катнашкан югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен һәм спортчыларга һәм спортчы-интрукторларга ярышларда алынган нәтиҗәләре өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләрне гамәлгә ашыруга акча 50 процент күләмендә оешма җитәкчесен стимуллаштырырга һәм 50 процент күләмендә оешма җитәкчесе урынбасарын стимуллаштырырга бүленә.

Физик культура һәм спорт өлкәсендә эшчәнлеген гамәлгә ашыручы өстәмә белем бирү оешмасы, һөнәри белем бирү оешмасы җитәкчесенә, җитәкчесе урынбасарларына тренер-укытучыларга ярышларда уңышлы катнашкан югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен һәм спортчыларга һәм спортчы-интрукторларга ярышларда алынган нәтиҗәләре өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр ай саен гамәлгә ашырыла.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

II бүлекнең 3 нче пунктындагы таблицаның 5 графасында «15 200» саннарын «17 000» саннарына алмаштырырга;

VI бүлектә:

1 нче пунктның 1.1 нче пунктчасындагы алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«хезмәт интенсивлылыгы өчен түләүләр;»;

4 нче пунктның 4.5 нче пунктчасында:

беренче, дүртенче, алтынчы абзацларда һәм 10 таблицаның исемендә «эшнең катлаулылыгы» сүзләрен «хезмәт интенсивлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

6 нчы пунктның 6.2 нче пунктчасында «гомуми белем бирү оешмаларының» сүзләрен «һөнәри белем бирү оешмаларының» сүзләренә алмаштырырга;

VII бүлекнең 1 нчы пунктындагы дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«нормаль шартлардан тайпылган шартларда эшләгән өчен түләүләр (төрле квалификациядәге эшләрне башкарганда, һөнәрләрне (вазыйфаларны), эш сәгатеннән тыш эшне, төнге вакытта эшне бергә башкаргада һәм нормаль шартлардан тайпылган башка шартларда эшләр башкарганда);»;

VIII бүлекнең 10 нчы пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Физик культура һәм спорт өлкәсендә эшчәнлеген гамәлгә ашыручы һөнәри белем бирү оешмасын гамәлгә куючы күрсәтелгән оешма җитәкчесенә тренер-укытучыларга ярышларда уңышлы катнашкан югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен һәм спортчыларга һәм спортчы-интрукторларга ярышларда алынган нәтиҗәләре өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр билгели ала.

Физик культура һәм спорт өлкәсендә эшчәнлеген гамәлгә ашыручы һөнәри белем бирү оешмасы җитәкчесе оешма җитәкчесе урынбасарларына тренер-укытучыларга ярышларда уңышлы катнашкан югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен һәм спортчыларга һәм спортчы-интрукторларга ярышларда алынган нәтиҗәләре өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр билгели ала.

Физик культура һәм спорт өлкәсендә эшчәнлеген гамәлгә ашыручы һөнәри белем бирү оешмасы җитәкчесенә, җитәкчесе урынбасарларына тренер-укытучыларга ярышларда уңышлы катнашкан югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен һәм спортчыларга һәм спортчы-интрукторларга ярышларда алынган нәтиҗәләре өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләрне гамәлгә ашыруга чираттагы финанс елына чыгымнар күләме Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәнең IX бүлегендәге 9 пункт нигезендә исәпләнә.

Физик культура һәм спорт өлкәсендә эшчәнлеген гамәлгә ашыручы i - нче һөнәри белем бирү оешмасы җитәкчесенә, җитәкчесе урынбасарларына тренер-укытучыларга ярышларда уңышлы катнашкан югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен һәм спортчыларга һәм спортчы-интрукторларга ярышларда алынган нәтиҗәләре өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләрне гамәлгә ашыруга акча 50 процент күләмендә оешма җитәкчесен стимуллаштырырга һәм 50 процент күләмендә оешма җитәкчесе урынбасарын стимуллаштырырга бүленә.

Физик культура һәм спорт өлкәсендә эшчәнлеген гамәлгә ашыручы һөнәри белем бирү оешмасы җитәкчесенә, җитәкчесе урынбасарларына тренер-укытучыларга ярышларда уңышлы катнашкан югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен һәм спортчыларга һәм спортчы-интрукторларга ярышларда алынган нәтиҗәләре өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр ай саен гамәлгә ашырыла.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы белем бирү оешмаларының эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләре, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

V бүлекнең 2 нче пунктындагы 2.1 нче пунктчада:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

$$«B_{kh} = O \times D_{kh} \times \frac{H_{fk}}{H_N},»;$$

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«O – әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган Татарстан Республикасы белем бирү оешмаларының эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләре, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләренең база оклады күләме;».

2. Физик культура һәм спорт өлкәсендә эшчәнлеген гамәлгә ашыручы өстәмә белем бирү оешмасы, һөнәри белем бирү оешмасы җитәкчесенә, җитәкчесе урынбасарларына тренер-укытучыларга ярышларда уңышлы катнашкан югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен һәм спортчыларга һәм спортчы-интрукторларга ярышларда алынган нәтиҗәләре өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр оешманың финанс-хуҗалык эшчәнлеге планнарында күрсәтелгән максатларга каралан, 2018 елның 1 гыйнварына торышы буенча билгеләнгән күләмнәрдә 2018 елның сентябрь – декабрь айларында башкарыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин